ГЛАВА ЧУКМАРЛИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САРМАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САРМАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЧУКМАРЛЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**2023 ел, 3 ноябрь** **№ 6**

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Чукмарлы авыл җирлегенең Нарат-Асты авылы гражданнарынын үзара салым акчаларын кертү җыенын билгеләү турында һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Чукмарлы авыл җирлеге Уставының 18.1 статьясы нигезендэ карар бирэм:

1. 2023 елның 15 ноябрендә 13.00 сәгатькә Сарман муниципаль районы, Нарат - Асты авылы, Нарат Асты урамы, 23 нче йорт адресы буенча урнашкан Нарат - Асты авылы медпункты бинасында, Сарман муниципаль районы Чукмарлы авыл җирлегенең Нарат-Асты торак пунктында 2024 елда гражданнарга үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: I төркем инвалидлардан, хәрби хезмәт үтүче гражданнардан, көндезге уку йортлары студентларыннан, махсус хәрби операциядә катнашучыларның гаилә әгъзаларыннан тыш, алынган акчалар җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә ризамы:

1) Нарат-Асты торак пунктында су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, чистартуны, транспортлауны һәм торак пунктында яшәүчеләргә су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (2 данә-кран , тоташтыру өчен торбалар сатып алу)

«ЭЙЕ» «Юк»?

3.Гражданнар жыенын оештыруныхэм  уздыруны Чукмарлы авыл жирлеге башкарма комитетына йоклэргэ

4.Әлеге карарны 7 көн эчендә «Сарман муниципаль районы», муниципаль берэмлекнен рэсми сайтына, «Интернет мәгълүмат» теле коммуникация челтэрендэ, Чукмарлы жирлеге  стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә,

5. Әлеге карар игълан ителгэн көннән үз көченә керә.

Чукмарлы авыл җирлеге башлыгы

Сарман муниципаль районы И. Х.Хадиуллин